БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-54-26, факс: (84368) 2-51-34. E-mail: Baltasi.Rayispolkom@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү**

**1.** Әлеге мәгълүмат белән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы «Смәел авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль план проекты (алга таба – проект) буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**

- текст формасында нигезләү материаллары;
- текст формасында нигезләү материаллары (ООС ГОиЧС );
- территориаль планлаштыру турында нигезләмә;
- объектларны растр форматында планлаштырып урнаштыру картасы;
- растр форматында җирлекнең функциональ зоналары картасы;
- растр форматында торак пунктларның чикләре картасы;
- растр форматындагы карталар рәвешендә нигезләү материаллары;
- растр форматындагы карталар рәвешендә нигезләү материаллары (ГОЧС)
- растр форматындагы карталар рәвешендә нигезләү материаллары (ЗОУИТ)
- растр форматындагы карталар рәвешендә нигезләү материаллары (ИИ и ТИ);
- гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр форматында карталар рәвешендә нигезләү буенча материаллар (ИПТ);
- растр форматындагы карталар рәвешендә нигезләү материаллары (ГОЧС);

**3. Проект буенча гавами тыңлаулар уздыру тәртибе һәм сроклары:**

Проект буенча гавами тыңлаулар 2025 елның 27 маеннан 2025 елның 14 июненә кадәр вакыт аралыгында уздырыла. Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:

- гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмат материалларын рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;

- проектны һәм аңа мәгълүмат материалларын рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;

- проект экспозицияләрен үткәрү;

- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышын үткәрү;

- гавами тыңлауларның беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;

- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;

- Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләре һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре;

- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарга хокук ияләре.

**5. Гавами тыңлаулар үткәрелә торган территория:** Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Смәел авыл җирлеге.

**6. Проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:**

- Смәел авылы, Бауман урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан Смәел авылы мәдәният йорты – 2025 елның 6 июнендә;

- Сизнер авылы, Советская урамы, 24 йорт адресы буенча урнашкан Сизнер авыл клубы – 2025 елның 6 июнендә;

- Бауман урамы, 69 йорт адресы буенча урнашкан «СП Смәел» ҖЧҖ идарәсе – 2025 елның 6 июнендә;

**7. Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:**

- 2025 елның 6 июненнән – 2025 елның 14 июненә кадәр вакыт аралыгында.

**8. Экспозицияләргә керү мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**

- эш көннәрендә 09.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр, төшке ял - 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр.

**9. Гавами тыңлауларда катнашучылар тарафыннан проектка кагылышлы түбәндәге искәрмәләр һәм кисәтүләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**

2025 елның 6 июненнән 2025 елның 14 июненә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $5^1$ статьясының 12 өлеше (алга таба - РФ ГрК) нигезендә узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт ярдәмендә;

- язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гавами тыңлауларны

оештыручысы адресына: 422250, Татарстан Республикасы, Балтач районы, Балтач шәһәр тибындагы поселогы, Ленин урамы, 42 йорт, тел. (84368) 2-51-34 (9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

- гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен китапта (журналда) исәпкә алу юлы белән, түбәндәге адрес буенча: 422258, Татарстан Республикасы, Балтач муниципаль районы, Смәел авылы, Бауман урамы, 50 йорт (9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр).

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының $5^1$ статьясының 12 өлеше нигезендә идентификацияләнгән гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру барышында язма рәвештә яки телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү хокукына ия.

**10. Гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 14 июнендә уздырырга:

- Смәел авылы, Бауман урамы, 50 йорт адресы буенча урнашкан Смәел авылы мәдәният йорты –14.00 сәгатьтә;

- Сизнер авылы, Советская урамы, 24 йорт адресы буенча урнашкан Сизнер авыл клубы –15.00 сәгатьтә;

**11. Проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) 2025 елның 6 июненнән “Район турында > Җирлекләр> Смәел авыл җирлеге >Шәһәр төзелеше >Авыл җирлеген территориаль планлаштыру документлары >Авыл җирлеген генераль планлаштыру документлары” битендә (https://baltasi.tatarstan.ru/doc_gp_sma) урнаштырылачак.

12. **Әлеге хәбәрнамәне** Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында **бастырып чыгарырга** (http://pravo.tatarstan.ru).

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов